ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д. ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**28 июнь 2024 ел** **№ 101**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендәге 144 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

2007 нче елның 2 нче мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнар, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 октябрендәге 144 нчы номерлы (2020 елның 26 февралендәге 158 нче номерлы, 2020 елның 20 ноябрендәге 8 нче номерлы, 2021 елның 2 сентябрендәге 30 нче номерлы, 2023 елның 7 апрелендәге 67 нче номерлы, 2023 елның 15 сентябрендәге 75 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчысы белән тулыландырырга:

«12) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүматларга билгеле булган, яллаучы вәкиле (эш бирүче) карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба анкетада булган мәгълүматлар) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә.»;

1.2. 6 нче статьяның 1 нче пунктындагы 8 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт

вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

1.3. 14 статьяның 3 нче пунктындагы 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;»;

1.4. 14 статьяның 4 пунктын «Мәгълүмат» сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасындагы мәгълүмати стендына, Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Красносельский авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенко